КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 20 май г.Казань № б-1007

Нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләре арасында хезмәттәшлекне арттыру, тармакара кооперацияне үстерү һәм Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру инструменты буларак цифрлы технологияләрне гамәлгә кертү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, «Татнефтехиминвест-холдинг» АҢ, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «ТАИФ» АҖ, «Нефтеконсорциум МНК» АҖ, «СИБУР» ҖЧҖ, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, «Казан дәүләт энергетика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы, «Татарстан Республикасының Сәнәгатьне үстерү фонды» АҖ, «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасының 2026 елның 26 – 28 августында «Казань Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге территориясендә түбәндәге чаралардан торган Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«КАЗАН: НЕФТЬ, ГАЗ, ХИМИЯ» халыкара нефть-газ химиясе күргәзмәсе;

Татарстан Республикасында девон нефте ачылуның 80 еллыгына багышланган «Технологик лидерлык һәм тотрыклы үсеш: киләчәк нефть-газ тармагы өчен инновацион алымнар һәм чишелешләр» халыкара фәнни-гамәли конференциясе;

А.И.Щеповский исемендәге «Сәнәгать экологиясе һәм иминлеге» XXI Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе;

«Россия Федерациясенең нефть-газ химиясе комплексы үсеше тенденцияләре һәм перспективалары» халыкара фәнни-гамәли конференциясе;

«Геодезиянең һәм геомәгълүмат системаларының актуаль мәсьәләләре» XV Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;

«Сыеклыклар һәм газлар чыгымнарын һәм микъдарын үлчәүне метрологик тәэмин итү буенча актуаль мәсьәләләр. Углеводород чималының (нефть һәм табигый газның) сыйфаты» XIII Халыкара метрологик конференциясе;

«Сәнәгать өчен кадрлар: хәзерге бурычлардан стратегик чишелешләргә» IX Гамәли HR-конференциясе;

«Төзелеш тармагында республика нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышы;

«Юл төзелешендә нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышы;

«Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате предприятиеләрен үстерү драйверы буларак тотрыклы энергетика» темасына түгәрәк өстәл утырышы;

«Яңа материаллар һәм химия» илкүләм проектын гамәлгә ашыру» темасына түгәрәк өстәл утырышы;

«Дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни үзәк кысаларында нефть-газ тармагы мәсьәләләрен чишү» темасына түгәрәк өстәл утырышы;

«Киләчәк белгечнең компетенцияләре» форсайт-сессиясе;

мәктәп укучылары өчен «ProSkills: һөнәрне сынап кара һәм сайла» һөнәри ориентация проекты;

Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 кысаларында иң яхшы проектка яки техник чишелешкә конкурс;

«Газпромбанк» АҖ эшлекле иртәнге ашы;

нефть-газ химиясе тармагы предприятиеләренең эш урыннары вакансияләре ярминкәсе;

Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 Яшьләр көне;

«Газпром» ГАҖнең тәэмин итүчеләр көне;

«Транснефть» ГАҖнең тәэмин итүчеләр көне;

«Газпром нефть» ГАҖнең тәэмин итүчеләр көне;

«СИБУР Холдинг» ГАҖнең тәэмин итүчеләр көне;

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖнең тәэмин итүчеләр көне.

2. Түбәндәгеләр составларын (боерыкка теркәләләр) расларга:

Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 оештыру комитеты;

Татарстан Республикасында девон нефте ачылуның 80 еллыгына багышланган «Технологик лидерлык һәм тотрыклы үсеш: киләчәк нефть-газ тармагы өчен инновацион алымнар һәм чишелешләр» халыкара фәнни-гамәли конференциясенең программа комитеты;

«Россия Федерациясенең нефть-газ химиясе комплексы үсеше тенденцияләре һәм перспективалары» халыкара фәнни-гамәли конференциясенең программа комитеты;

«Геодезиянең һәм геомәгълүмат системаларының актуаль мәсьәләләре» XV Халыкара фәнни-гамәли конференциясенең программа комитеты;

«Сыеклыклар һәм газлар чыгымнарын һәм микъдарын үлчәүне метрологик тәэмин итү буенча актуаль мәсьәләләр. Углеводород чималының (нефть һәм табигый газның) сыйфаты» XIII Халыкара метрологик конференциясенең программа комитеты.

3. Түбәндәгеләр өчен җаваплы итеп билгеләүне тәкъдим итәргә:

«КАЗАН: НЕФТЬ, ГАЗ, ХИМИЯ» халыкара нефть-газ химиясе күргәзмәсен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министерлыгы;

Татарстан Республикасында девон нефте ачылуның 80 еллыгына багышланган «Технологик лидерлык һәм тотрыклы үсеш: киләчәк нефть-газ тармагы өчен инновацион алымнар һәм чишелешләр» халыкара фәнни-гамәли конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – В.Д.Шашин исемендәге ПАО «Татнефть» (Татар геология-разведка идарәсе), «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе;

А.И.Щеповский исемендәге «Сәнәгать экологиясе һәм иминлеге» XXI Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министерлыгы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе;

«Россия Федерациясенең нефть-газ химиясе комплексы үсеше тенденцияләре һәм перспективалары» халыкара фәнни-гамәли конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ;

«Геодезиянең һәм геомәгълүмат системаларының актуаль мәсьәләләре» XV Халыкара фәнни-гамәли конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе;

«Сыеклыклар һәм газлар чыгымнарын һәм микъдарын үлчәүне метрологик тәэмин итү буенча актуаль мәсьәләләр. Углеводород чималының (нефть һәм табигый газның) сыйфаты» XIII Халыкара метрология конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы;

«Сәнәгать өчен кадрлар: хәзерге бурычлардан стратегик чишелешләргә» IX Гамәли HR-конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ;

«Төзелеш тармагында республика нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе;

«Юл төзелешендә нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы

Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе;

«Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате предприятиеләрен үстерү драйверы буларак тотрыклы энергетика» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – «Казан дәүләт энергетика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе;

«Яңа материаллар һәм химия» илкүләм проектын гамәлгә ашыру» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет белем бирү учреждениесе;

«Дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни үзәк кысаларында нефть-газ тармагы мәсьәләләрен чишү» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе;

«Киләчәк белгечнең компетенцияләре» форсайт-сессиясен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Дөньякүләм нефть советының Россия милли комитеты» ассоциациясе, «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;

мәктәп укучылары өчен «ProSkills: һөнәрне сынап кара һәм сайла» һөнәри ориентация проектын әзерләү һәм үткәрү өчен – «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;

Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 кысаларында иң яхшы проектка яки техник чишелешкә конкурс әзерләү һәм үткәрү өчен – «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы;

«Газпромбанк» АҖнең эшлекле иртәнге ашын әзерләү һәм үткәрү өчен – «Газпромбанк» АҖ, «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;

нефть-газ химиясе тармагы предприятиеләренең эш урыннары вакансияләре ярминкәсен әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 Яшьләр көнен әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы, «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, «Нефть югары мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» югары белем бирү дәүләт бюджет белем бирү учреждениесе;

«Газпром» ГАҖнең тәэмин итүчеләр көнен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;

«Транснефть» ГАҖнең тәэмин итүчеләр көнен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Транснефть» ГАҖ, «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;

«Газпром нефть» ГАҖнең тәэмин итүчеләр көнен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Газпром нефть» ГАҖ, «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;

«СИБУР Холдинг» ГАҖнең тәэмин итүчеләр көнен әзерләү һәм үткәрү өчен – «СИБУР Холдинг» ГАҖ, «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖнең тәэмин итүчеләр көнен әзерләү һәм үткәрү өчен – В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ (Логистика үзәге), Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;

Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 эшлекле программасын әзерләү һәм үткәрү өчен – «Татарстан Республикасының Сәнәгатьне үстерү фонды» АҖ, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы.

4. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы, «Татарстан Республикасының Сәнәгать үсеше фонды» АҖ һәм «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы белән берлектә, 2026 елның 25 маена кадәр түбәндәгеләрне эшләргә һәм Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 оештыру комитетына раслауга кертергә:

Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 чаралары программасын;

әлеге чараларны оештыру һәм үткәрү чыгымнары сметасын.

5. В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «ТАИФ» АҖ, «Нефтеконсорциум МНК» АҖ, «СИБУР» ҖЧҖнең Татарстан Республикасында девон нефте ачылуның 80 еллыгына багышланган «Технологик лидерлык һәм тотрыклы үсеш: киләчәк нефть-газ тармагы өчен инновацион алымнар һәм чишелешләр» халыкара фәнни-гамәли конференциясен, А.И.Щеповский исемендәге «Сәнәгать экологиясе һәм иминлеге» XXI Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясен, «Геодезиянең һәм геомәгълүмат системаларының актуаль мәсьәләләре» XV Халыкара фәнни-гамәли конференциясен, «Сыеклыклар һәм газлар чыгымнарын һәм микъдарын үлчәүне метрологик тәэмин итү буенча актуаль мәсьәләләр. Углеводород чималының (нефть һәм табигый газның) сыйфаты» XIII Халыкара метрология конференциясен, «Сәнәгать өчен кадрлар: хәзерге бурычлардан стратегик чишелешләргә» IX Гамәли HR-конференциясен, «Төзелеш тармагында республика нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышын, «Юл төзелешендә нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышын, «Дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни үзәк кысаларында нефть-газ тармагы мәсьәләләрен чишү» темасына түгәрәк өстәл утырышын, Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 Яшьләр көнен әзерләү һәм үткәрүне финанслау турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

6. Республика башкарма хакимият органнарына Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтергә, шулай ук Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе комплексы оешмаларына – ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы белән берлектә, Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 үткәрелә торган урыннарда хокук тәртибен һәм җәмәгатьчелек иминлеген тәэмин итүдә чараларны оештыручыларга ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

8. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 үткәрүне мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.

9. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, шулай ук бу боерыкның 3 пунктында чараларны әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы буларак күрсәтелгән министрлыкларга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 20 май, б-1007 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2026 оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, оештыру комитеты рәисе |
| Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Адиев Эльдар Рәшит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының нефть-газ химиясе комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, оештыру комитеты сәркатибе |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдуллаҗанов Эдвард Юныс улы | «Казан дәүләт энергетика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Бохараев Марат Зөфәр улы | «Татарстан Республикасының Сәнәгать үсеше фонды» АҖ директоры (килешү буенча) |
| Галиев Ренат Марат улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Гатиятуллин Нәкыйп Сәлах улы | «Файдалы казылмалар запаслары буенча дәүләт комиссиясе» федераль бюджет учреждениесенең Казан филиалы директоры (килешү буенча) |
| Гуськов Дмитрий Владимирович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Җиһаншин Азат Илдус улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры |

| | |
|---|---|
| Казаков Юрий Михайлович | «Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Лунегов Дмитрий Алексеевич | «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Мәганов Наил Өлфәт улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Минһаҗев Рафаэль Рафис улы | «Нефтеконсорциум МНК» АҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Миннегалиев Роберт Хәмит улы | «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнеханов Рифкать Нургали улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты |
| Начвин Илья Сергеевич | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Охоткин Кирилл Германович | «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Прытков Евгений Александрович | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Руденко Евгений Анатольевич | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин Айрат Фоат улы | «Казаньоргсинтез» ГАҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Сафин Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Тайбинский Алексей Семенович | Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Тәхәветдинов Шәфәгать Фәхраз улы | Татарстан Республикасы Рәисенең нефть сәнәгате мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Фәләхов Марат Инил улы | «Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Фәсхетдинов Марат Гайсә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигать ресурсларыннан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шахов Алексей Алексеевич | «СИБУР» ҖЧҖ директоры (дәүләт органнары белән элемтә, була торган төбәкләрнең социаль-икътисадый үсешенә ярдәм күрсәтү) (килешү буенча) |
| Яруллин Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ генераль директоры (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 20 май, б-1007 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында девон нефте ачылуның 80 еллыгына агышланган «Технологик лидерлык һәм тотрыклы үсеш: киләчәк нефть-газ тармагы өчен инновацион алымнар һәм чишелешләр» халыкара фәнни-гамәли конференциясенең программа комитеты составы

| | |
|---|---|
| Мөслимов Ренат Хәлиулла улы | Татарстан Республикасы Рәисенең нефть һәм нефть-газ ятмаларын эшкәртү мәсьәләләре буенча консультанты, программа комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Мәганов Наил Өлфәт улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ генераль директоры, программа комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гыйләҗева Татьяна Владимировна | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ПАҖ Татарстан геология-разведка идарәсенең тышкы коммуникацияләр буенча баш белгече, программа комитеты сәркатибе (килешү буенча) |

Программа комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әбҗәлилова Ләйсән Рәхим кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе вице-президенты |
| Әфләтунов Ринат Рәкыйп улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ генераль директоры урынбасары – баш геолог (килешү буенча) |
| Бачков Альберт Петрович | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖнең нефть һәм газ ятмалары геологиясе идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Дьяконов Александр Анатольевич | «Нефть югары мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» югары белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры |

| | |
|---|---|
| Замрий Анатолий Владимирович | Россия Нефть-газ сәнәгатьчеләре берлеге советы рәисенең беренче урынбасары, Россия Нефть-газ сәнәгатьчеләре берлегенең тармакара эксперт-аналитика үзәге башкарма директоры, Мәскәү шәһәре (килешү буенча) |
| Крюков Валерий Анатольевич | Россия фәннәр академиясе академигы, Ресурс икътисады үзәгенең баш фәнни хезмәткәре, «ЭКО» бөтенроссия икътисадый журналының баш мөхәррире, Новосибирск шәһәре (килешү буенча) |
| Куликов Андрей Владимирович | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гамәли тикшеренүләр институты» аерымланган структур бүлекчәсе директоры |
| Нургалиев Данис Карлович | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең нефть-газ технологияләре, табигатьтән файдалану һәм Җир турында фәннәр юнәлешләре буенча проректоры (килешү буенча) |
| Пименов Андрей Александрович | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ПАҖнең Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проектлау институты (ТатНИПИнефть) директоры (килешү буенча) |
| Прищепа Олег Михайлович | «Императрица Екатерина II Санкт-Петербург тау университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни эшчәнлек буенча проректоры |
| Соколов Александр Владимирович | «Георесурсы» журналының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Судаков Владислав Анатольевич | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институты директорының инновацион эшчәнлек буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Тудвачев Алексей Викторович | «Санкт-Петербург дәүләт университетының Су үзәге» ҖЧҖ генераль директоры, Россия Федерациясендәге гидрогеологларның халыкара ассоциациясе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шаһидуллин Рифгать Роальд улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре институты» аерымланган структур бүлекчәсе башлыгы |
| Шмаль Генадий Иосифович | Россия нефть сәнәгатьчеләре берлеге президенты, Мәскәү шәһәре (килешү буенча) |
| Шпуров Игорь Викторович | «Файдалы казылмалар запаслары буенча дәүләт комиссиясе» федераль бюджет учреждениесе генераль директоры (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 20 май, б-1007 нче
боерыгы белән расланды

«Россия Федерациясенең нефть-газ химиясе комплексы үсеше тенденцияләре һәм перспективалары» халыкара фәнни-гамәли конференциясенең программа комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Яруллин Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ генераль директоры, программа комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Салихов Илфат Зилбир улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ генераль директоры урынбасары, программа комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Адиев Эльдар Рәшит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының нефть-газ химиясе комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, программа комитеты сәркатибе |

Программа комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтова Ирина Гәрәй кызы | «Казан дәүләт энергетика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең үсеш һәм инновацияләр буенча проректоры (килешү буенча) |
| Мәганов Наил Өлфәт улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Миннегулов Фәрид Гертович | «ТАИФ» АҖ идарәсе рәисенең нефть химиясе буенча киңәшчесе (килешү буенча) |
| Миңнеханов Рифкать Нургали улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты |
| Палей Руслан Владимирович | «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең «Промхимтех» алдынгы инженерлык мәктәбе директоры (килешү буенча) |
| Сафин Айрат Фоат улы | «Казаньоргсинтез» ГАҖ генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Фәләхов Марат Инил улы | «Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ генераль директоры (килешү буенча). |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 20 май, б-1007 нче
боерыгы белән расланды

«Геодезиянең һәм геомәгълүмат системаларының актуаль мәсьәләләре»
XV Халыкара фәнни-гамәли конференциясенең программа комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Әһлиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры, программа комитеты рәисе |
| Лунегов Дмитрий Алексеевич | «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, программа комитеты рәисе урынбасары |
| Бахматов Сергей Юрьевич | «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе директорының беренче урынбасары, программа комитеты сәркатибе |

Программа комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Алишев Тимерхан Булат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең тышкы элемтәләр буенча проректоры (килешү буенча) |
| Безменов Владимир Михайлович | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең астрономия һәм космос геодезиясе кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Гыйлаев Дамир Мөнзил улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖнең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсенә караган Топография-геодезия һәм маркшейдерлык эшләре идарәсе башлыгы урынбасары – топография-геодезия һәм маркшейдерлык эшләре бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Кәримов Илсур Рәис улы | «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалы директоры (килешү буенча) |
| Кыямов Алмаз Әхтәм улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Огородников Алексей Игоревич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүматны саклау идарәсе башлыгы |
| Сөләйманов Салават Рәҗәп улы | «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет учреждениесенең җир төзелеше һәм кадастрлар кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Фәсхетдинов Марат Гайсә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигать ресурсларыннан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы. |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 20 май, б-1007 нче боерыгы белән расланды

«Сыеклыклар һәм газлар чыгымнарын һәм микъдарын үлчәүне метрологик тәэмин итү буенча актуаль мәсьәләләр. Углеводород чималының (нефть һәм табигый газның) сыйфаты» XIII Халыкара метрологик конференциясенең программа комитеты составы

| | |
|---|---|
| Зарипов Наил Шамил улы | Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директоры, программа комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Пронин Антон Николаевич | «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры, программа комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Тайбинский Алексей Семенович | Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директоры урынбасары, программа комитеты секретаре (килешү буенча) |

Программа комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Вәгыйзов Рөстәм Шаһит улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ баш метрологы (килешү буенча) |
| Горчев Александр Иванович | Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директорының фән буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Ненашкина Светлана Валентиновна | Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директоры урынбасары – баш бухгалтеры (килешү буенча). |

___